СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2021 елның 27 мае № 9/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының аерым муниципаль норматив актларына үзгәрешләр кертү турында

Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2006 елның 29 декабрендәге 12/4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен һәм муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә, «аның кредиторлары белән исәп-хисаплар тәгәлләнгән» сүзләреннән соң **1 нче кушымтаның 7.4 пунктындагы 1 пунктчасының икенче абзацына** «, юридик зат бетерелүгә бәйле рәвештә эштән азат ителә торган хезмәткәрләр өчен Россия Федерациясенең хезмәт законнарында каралган барлык түләүләр башкарылган» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 25 апрелендәге 35/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**4.1 пунктта:**

**5 пунктчасын** түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) диңгез портлары, елга портлары, махсус портлар, аларның инфраструктурасы объектлары, шул исәптән ясалма җир кишәрлекләре, порт гидротехник корылмалары, федераль милектә булырга мөмкин булган диңгез порты инфраструктурасы объектларыннан тыш, шәхси милеккә читләштерелергә тиеш түгел;»;

түбәндәге эчтәлекле **21 пунктча өстәргә:**

«21) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмалар объектлары.».

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 23 октябрендәге 38/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет

процессы турындагы Нигезләмәгә, **9 статьяның икенче абзацы һәм 18 статьяның икенче абзацы** үз көчен югалткан дип танып, үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге Карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров